**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О регулировании в Республике Татарстан отдельных вопросов увековечения памяти погибших при защите Отечества

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
8 июня 2026 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Законом Российской Федерации от 14 января 1993 года № 4292-I «Об увековечении памяти погибших при защите Отечества», Федеральным законом от 19 мая 1995 года № 80-ФЗ «Об увековечении Победы советского народа в Великой Отечественной войне 1941 – 1945 годов», иными федеральными законами регулирует в Республике Татарстан отдельные вопросы увековечения памяти погибших при защите Отечества.

Статья 2. **Увековечение памяти погибших при защите Отечества**

1. Увековечению подлежит память:
погибших в ходе военных действий, при выполнении других боевых задач или при выполнении служебных обязанностей по защите Отечества;
погибших при выполнении воинского долга на территориях других государств;
умерших от ран, контузий, увечий или заболеваний, полученных при защите Отечества, независимо от времени наступления указанных последствий, а также пропавших без вести в ходе военных действий, при выполнении других боевых задач или при выполнении служебных обязанностей;
погибших, умерших в плену, в котором оказались в силу сложившейся боевой обстановки, но не утративших своей чести и достоинства, не изменивших Родине.
2. Действие настоящего Закона распространяется также на увековечение памяти погибших (умерших от ран, контузий, увечий или заболеваний) при выполнении задач в ходе специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области или выполнении задач по отражению вооруженного вторжения на территорию Российской Федерации, в ходе вооруженной провокации на Государственной границе Российской Федерации

и приграничных территориях субъектов Российской Федерации, прилегающих к районам проведения специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области.

3. Дань памяти воздается также иностранным гражданам, погибшим при защите России.

4. Увековечению подлежит память объединений, соединений и организаций, отличившихся при защите Отечества, а также увековечиваются места боевых действий, вошедшие в историю как символы героизма, мужества и стойкости народов нашего Отечества.

### Статья 3. **Формы увековечения памяти погибших при защите Отечества**

1. В Республике Татарстан увековечение памяти погибших при защите Отечества осуществляется в формах, установленных Законом Российской Федерации от 14 января 1993 года № 4292-I «Об увековечении памяти погибших при защите Отечества», иными федеральными законами и законами Республики Татарстан, в том числе в формах:

1) захоронения и перезахоронения останков погибших при защите Отечества, сохранения и благоустройства воинских захоронений, создания, сохранения и благоустройства других мест погребения погибших при защите Отечества, установки надгробий, памятников, стел, обелисков, других мемориальных сооружений и объектов, увековечивающих память погибших при защите Отечества;

2) сохранения и обустройства отдельных территорий, исторически связанных с подвигами погибших при защите Отечества;

3) публикаций в средствах массовой информации и в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» материалов о погибших при защите Отечества, создания произведений искусства и литературы, посвященных их подвигам, организации выставок;

4) присвоения имен погибших при защите Отечества улицам и площадям, географическим объектам, государственным и муниципальным организациям, в том числе образовательным;

5) занесения имен погибших при защите Отечества и других сведений о них в Книгу Памяти Республики Татарстан.

2. По решению органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления, общественно-государственных объединений, общественных объединений, организаций в Республике Татарстан могут осуществляться иные мероприятия по увековечению памяти погибших при защите Отечества.

### Статья 4. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан по увековечению памяти погибших при защите Отечества**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан по увековечению памяти погибших при защите Отечества относятся:

1) законодательное регулирование отдельных вопросов увековечения памяти погибших при защите Отечества;

2) установление памятных дат Республики Татарстан в целях увековечения памяти погибших при защите Отечества;

3) осуществление контроля за соблюдением законодательства Республики Татарстан об увековечении памяти погибших при защите Отечества;

4) иные полномочия в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям органов исполнительной власти Республики Татарстан по увековечению памяти погибших при защите Отечества относятся:

1) принятие нормативных правовых актов Республики Татарстан в целях реализации в Республике Татарстан мероприятий по увековечению памяти погибших при защите Отечества в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан;

2) утверждение порядка ведения и хранения Книги Памяти Республики Татарстан;

3) осуществление мероприятий по увековечению памяти погибших при защите Отечества, в том числе принятие решений о захоронении непогребенных останков погибших при защите Отечества и (или) решений о перемещении неизвестных воинских захоронений;

4) обеспечение проведения всех необходимых мероприятий по захоронению (перезахоронению) останков погибших при защите Отечества в части, не отнесенной нормативными правовыми актами Российской Федерации к полномочиям иных органов публичной власти;

5) взаимодействие в пределах своей компетенции с федеральными органами государственной власти, органами местного самоуправления, общественно-государственными объединениями, общественными объединениями, организациями, уполномоченными на проведение поисковых работ, по вопросам увековечения памяти погибших при защите Отечества;

6) формирование поименных списков погибших при защите Отечества, останки которых погребены в воинских захоронениях, находящихся на территории Республики Татарстан;

7) установление ограничения в виде запрета на проведение строительных, земляных, дорожных и других работ, в результате которых неизвестные воинские захоронения могут быть повреждены или перемещены с места обнаружения;

8) сохранение и реставрация памятников Великой Отечественной войны регионального значения, поддержание их в состоянии, соответствующем достойному и уважительному отношению к памяти о Победе советского народа в Великой Отечественной войне;

9) содействие популяризации событий, фактов и личностей, в честь которых установлены надгробия, памятники, стелы, обелиски, другие мемориальные сооружения и объекты, увековечивающие память погибших при защите Отечества;

10) установка информационных надписей и обозначений на памятники Великой Отечественной войны, воинские захоронения, находящиеся в ведении Республики Татарстан;

11) иные полномочия в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

3. Полномочия, указанные в части 2 настоящей статьи, осуществляются Кабинетом Министров Республики Татарстан или уполномоченным (уполномоченными) им органом (органами) исполнительной власти Республики Татарстан.

Статья 5. **Полномочия органов местного самоуправления по увековечению памяти погибших при защите Отечества**

К полномочиям органов местного самоуправления по увековечению памяти погибших при защите Отечества относятся:

1) осуществление мероприятий по содержанию в порядке и благоустройству воинских захоронений, мемориальных сооружений и объектов, увековечивающих память погибших при защите Отечества, которые находятся на территориях соответствующих муниципальных образований, а также работ по реализации межправительственных соглашений по уходу за захоронениями иностранных военнослужащих на территории Республики Татарстан;

2) ведение учета воинских захоронений, находящихся на территориях соответствующих муниципальных образований;

3) создание резерва площадей для новых воинских захоронений;

4) осуществление взаимодействия с уполномоченным федеральным органом исполнительной власти по увековечению памяти погибших при защите Отечества в целях организации централизованного учета мемориальных сооружений, находящихся вне воинских захоронений и содержащих Вечный огонь или Огонь памяти;

5) установка информационных надписей и обозначений на памятники Великой Отечественной войны, воинские захоронения, находящиеся в ведении органов местного самоуправления;

6) сохранение и реставрация памятников Великой Отечественной войны местного (муниципального) значения, поддержание их в состоянии, соответствующем достойному и уважительному отношению к памяти о Победе советского народа в Великой Отечественной войне;

7) иные полномочия в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 6. **Книга Памяти Республики Татарстан**

1. В целях формирования и укрепления у граждан уважения к отечественной истории и увековечения памяти погибших при защите Отечества издается Книга Памяти Республики Татарстан.

2. Порядок ведения и хранения Книги Памяти Республики Татарстан утверждается Кабинетом Министров Республики Татарстан или уполномоченным им органом исполнительной власти Республики Татарстан.

3. Органы местного самоуправления вправе издавать книги Памяти муниципальных образований Республики Татарстан в порядке, установленном муниципальными нормативными правовыми актами.

Статья 7. **Порядок присвоения имен погибших при защите Отечества государственным и муниципальным организациям, улицам и площадям, географическим объектам**

1. Присвоение имен погибших при защите Отечества организациям, учредителем которых является Республика Татарстан, осуществляется в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.

2. Присвоение имен погибших при защите Отечества организациям, учредителем которых является соответствующее муниципальное образование, осуществляется в порядке, установленном муниципальными нормативными правовыми актами.

3. Присвоение имен погибших при защите Отечества улицам и площадям осуществляется в порядке, установленном муниципальными нормативными правовыми актами.

4. Присвоение имен погибших при защите Отечества географическим объектам, находящимся на территории Республики Татарстан, осуществляется в соответствии с Федеральным законом от 18 декабря 1997 года № 152-ФЗ «О наименованиях географических объектов».

Статья 8. **Обеспечение сохранности памятников Великой Отечественной войны, воинских захоронений, находящихся на территории Республики Татарстан**

1. К памятникам Великой Отечественной войны относятся скульптурные, архитектурные и другие мемориальные сооружения и объекты, увековечивающие память о событиях, об участниках, о ветеранах и жертвах Великой Отечественной войны, в том числе захоронения погибших при защите Отечества в годы Великой Отечественной войны и захоронения жертв Великой Отечественной войны с находящимися на указанных захоронениях надгробиями, памятниками, стелами, обелисками, элементами ограждения и другими мемориальными сооружениями и объектами.

2. На памятник Великой Отечественной войны должны быть установлены надписи и обозначения, содержащие информацию о памятнике Великой Отечественной войны. Информационные надписи и обозначения должны включать в себя историческую справку, содержащую сведения о событиях, в честь которых были установлены памятники Великой Отечественной войны, информацию о подвиге погибших при защите Отечества и иные сведения (включая исторические документы и фотоматериалы). Информационные надписи и обозначения также могут включать в себя графические идентификаторы – QR-коды, посредством которых обеспечивается переход на информационные ресурсы в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», содержащие историческую справку,

видеоматериалы и другие материалы о произошедших событиях и об указанных лицах.

3. Уполномоченные органы исполнительной власти Республики Татарстан и органы местного самоуправления в пределах своих полномочий ответственны за сохранение памятников Великой Отечественной войны, поддержание их в состоянии, соответствующем достойному и уважительному отношению к памяти о Победе советского народа в Великой Отечественной войне.

4. Сохранение и реставрация памятников Великой Отечественной войны обеспечиваются выделением средств из бюджета Республики Татарстан на памятники регионального значения и местных бюджетов – на памятники местного (муниципального) значения, а также пожертвованиями физических и юридических лиц.

5. Захоронения погибших при защите Отечества с находящимися на них надгробиями, памятниками, стелами, обелисками, элементами ограждения и другими мемориальными сооружениями и объектами являются воинскими захоронениями.

6. На воинское захоронение должны быть установлены надписи и обозначения, содержащие информацию о воинском захоронении. Информационные надписи и обозначения должны включать в себя историческую справку, содержащую сведения о событиях, в честь которых были установлены мемориальные сооружения и объекты, информацию о подвиге погибших при защите Отечества и иные сведения (включая исторические документы и фотоматериалы). Информационные надписи и обозначения также могут включать в себя графические идентификаторы – QR-коды, посредством которых обеспечивается переход на информационные ресурсы в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», содержащие историческую справку, видеоматериалы и другие материалы о произошедших событиях и об указанных лицах.

7. Обязанность по установке информационных надписей и обозначений на памятники Великой Отечественной войны, воинские захоронения возлагается на уполномоченные органы исполнительной власти Республики Татарстан и органы местного самоуправления, в ведении которых находятся соответствующие памятники Великой Отечественной войны и воинские захоронения.

8. В целях обеспечения сохранности воинских захоронений, признанных объектами культурного наследия (памятниками истории и культуры) народов Российской Федерации, в местах, где они расположены, устанавливаются зоны охраны объектов культурного наследия в порядке, определяемом законодательством Российской Федерации.

9. Строительство, реконструкция, капитальный ремонт объекта капитального строительства, в результате которых могут быть повреждены воинские захоронения, проводятся в соответствии с требованиями законодательства о градостроительной деятельности, а земляные, дорожные и другие работы, в результате которых могут быть повреждены воинские захоронения, проводятся только после согласования с органами местного самоуправления.

10. Пришедшие в негодность воинские захоронения, мемориальные сооружения и объекты, увековечивающие память погибших при защите Отечества, подлежат восстановлению органами местного самоуправления.

11. Граждане и юридические лица несут ответственность за сохранность воинских захоронений, находящихся на земельных участках, правообладателями которых они являются.

Статья 9. **Просвещение в сфере увековечения памяти погибших при защите Отечества**

1. В Республике Татарстан в целях воспитания у молодежи уважения к отечественной истории и истории родного края, гордости за Российскую Федерацию и Республику Татарстан, сохранения исторической преемственности поколений, пропаганды подвигов, героизма и мужества погибших при защите Отечества проводятся мероприятия, в том числе уроки мужества, открытые лекции, по просвещению в сфере увековечения памяти погибших при защите Отечества.

2. Мероприятия, указанные в части 1 настоящей статьи, проводятся с соблюдением требований, предусмотренных законодательством Российской Федерации, и могут быть приурочены к дням воинской славы и памятным датам России, памятным датам Республики Татарстан.

Статья 10. **Финансовое обеспечение мероприятий по увековечению памяти погибших при защите Отечества**

Расходы на проведение мероприятий, связанных с увековечением памяти погибших при защите Отечества, в том числе на устройство отдельных территорий и объектов, исторически связанных с подвигами защитников Отечества, а также на организацию выставок и других мероприятий осуществляются за счет средств бюджета Республики Татарстан и местных бюджетов в соответствии с компетенцией органов государственной власти и органов местного самоуправления, а также за счет иных источников, не запрещенных законодательством Российской Федерации.

Статья 11. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
19 июня 2026 года
№ 36-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүнең аерым мәсьәләләрен Татарстан Республикасында җайга салу турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 8 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-I номерлы Россия Федерациясе Законы, «1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында совет халкының Җиңүен мәңгеләштерү турында» 1995 елның 19 маендагы 80-ФЗ номерлы Федераль закон, бүтән федераль законнар нигезендә Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүнең аерым мәсьәләләрен Татарстан Республикасында җайга сала.

2 статья. **Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү**

1. Түбәндәгеләр истәлеге мәңгеләштерелергә тиеш:
Ватанны саклау буенча хәрби хәрәкәтләр барышында, башка хәрби бурычларны үтәгәндә яисә хезмәт йөкләмәләрен үтәгәндә һәлак булганнар;
башка дәүләтләр территорияләрендә хәрби бурычны үтәгәндә һәлак булганнар;
Ватанны саклаганда алынган яралардан, контузияләрдән, гарипләнүләрдән яисә авырулардан, күрсәтелгән нәтиҗәләрнең кайчан барлыкка килүенә карамастан, вафат булганнар, шулай ук хәрби хәрәкәтләр барышында, башка хәрби бурычларны үтәгәндә яисә хезмәт йөкләмәләрен үтәгәндә хәбәрсез югалганнар;
барлыкка килгән хәрби шартлар аркасында тоткынлыкка эләгеп һәлак булганнар, вафат булганнар, ләкин үз намусын һәм вөҗданын югалтмаганнар, Туган иленә хыянәт итмәгәннәр.
2. Әлеге Законның гамәлдә булуы шулай ук Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе

территорияләрендә махсус хәрби операция барышында бурычлар үтәгәндә яисә Россия Федерациясе территориясенә коралллы басып керүгә каршы тору буенча, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычлар үтәгәндә һәлак булганнар (яралардан, контузияләрдән, гарипләнүләрдән яисә авырулардан вафат булганнар) истәлеген мәңгеләштерүгә дә кагыла.

3. Россияне саклаганда һәлак булган чит ил гражданнары шулай ук ихтирам белән искә алына.

4. Ватанны саклаганда аерым батырлык күрсәткән берләшмәләр, кушылмалар һәм оешмалар истәлеге мәңгеләштерелергә тиеш, шулай ук Ватаныбыз халыкларының каһарманлыгы, батырлыгы һәм ныклыгы символлары буларак тарихка кереп калган хәрби хәрәкәтләр урыннары мәңгеләштерелә.

### 3 статья. **Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү рәвешләре**

1. Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү Татарстан Республикасында «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-I номерлы Россия Федерациясе Законында, бүтән федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән рәвешләрдә, шул исәптән түбәндәге рәвешләрдә, гамәлгә ашырыла:

1) Ватанны саклаганда һәлак булганнар җәсәдләрен күмү һәм яңадан күмү, хәрби каберлекләрне саклап калу һәм төзекләндерү, Ватанны саклаганда һәлак булганнар җирләнгән башка урыннарны саклап калу һәм төзекләндерү, Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүче кабер ташлары, һәйкәлләр, стелалар, обелисклар, башка мемориаль корылмалар һәм объектлар урнаштыру;

2) Ватанны саклаганда һәлак булганнарның батырлыклары белән тарихи бәйләнеше булган аерым территорияләрне саклап калу һәм төзекләндерү;

3) Ватанны саклаганда һәлак булганнар турындагы материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару, аларның батырлыкларына багышланган сәнгать һәм әдәбият әсәрләрен булдыру, күргәзмәләр оештыру;

4) урамнарга һәм мәйданнарга, географик объектларга, дәүләт оешмаларына һәм муниципаль оешмаларга, шул исәптән мәгариф оешмаларына, Ватанны саклаганда һәлак булганнар исемнәрен бирү;

5) Ватанны саклаганда һәлак булганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның исемнәрен һәм алар турында башка белешмәләрне Татарстан Республикасы Хәтер китабына кертү.

2. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, иҗтимагый-дәүләти берләшмәләр, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар карары буенча Ватанны саклаганда һәлак

булганнар истәлеген мәңгеләштерүнең башка чаралары гамәлгә ашырылырга мөмкин.

4 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү буенча вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүнең аерым мәсьәләләрен законнар белән җайга салу;

2) Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасының истәлекле даталарын билгеләү;

3) Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү хакында Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

4) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү чараларын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү;

2) Татарстан Республикасы Хәтер китабын алып бару һәм саклау тәртибен раслау;

3) Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү чараларын гамәлгә ашыру, шул исәптән Ватанны саклаганда һәлак булганнарның җирләнмәгән җәсәдләрен күмү турында карарлар һәм (яисә) билгесез хәрби каберлекләрне күчерү турында карарлар кабул итү;

4) Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән бүтән гавами хакимият органнары вәкаләтләренә кертеп каралмаган өлешендә Ватанны саклаганда һәлак булганнарның җәсәдләрен күмү (яңадан күмү) буенча барлык тиешле чаралар үткәрүне тәэмин итү;

5) Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча федераль дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый-дәүләти берләшмәләр, иҗтимагый берләшмәләр, эзләү эшләрен алып баруга вәкаләтле оешмалар белән үз компетенциясе чикләрендә үзара хезмәттәшлек итү;

6) Татарстан Республикасы территориясендәге хәрби каберлекләргә җәсәдләре җирләнгән Ватанны саклаганда һәлак булганнарның исемнәре язылган исемлекләр төзү;

7) билгесез хәрби каберлекләргә зыян килү яисә табылу урыныннан күчерү ихтималы булган төзелеш, җир, юл эшләрен һәм башка эшләрне башкаруга тыю рәвешендә чикләү билгеләү;

8) региональ әһәмияттәге Бөек Ватан сугышы һәйкәлләрен саклап калу һәм реставрацияләү, аларны Бөек Ватан сугышында совет халкының Җиңүе турында истәлеккә карата лаеклы һәм ихтирамлы мөнәсәбәтне күрсәткән хәлдә тоту;

9) Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүче кабер ташлары, һәйкәлләр, стелалар, обелисклар, башка мемориаль корылмалар һәм объектлар урнаштыру өчен нигез булган вакыйгаларны, фактларны һәм шәхесләрне популярлаштыруга булышлык күрсәтү;

10) Татарстан Республикасы карамагындагы Бөек Ватан сугышы һәйкәлләренә, хәрби каберлекләргә мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру;

11) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә ул вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (органнары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Җирле үзидарә органнарының Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү буенча вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарының Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендәге Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүче хәрби каберлекләрне, мемориаль корылмаларны һәм объектларны тәртиптә тоту һәм төзекләндерү чараларын, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә чит ил хәрби хезмәткәрләре каберлекләрен карап тору буенча хөкүмәтара килешүләрне гамәлгә ашыру эшләрен башкару;

2) тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендәге хәрби каберлекләрнең исәбен алып бару;

3) яңа хәрби каберлекләр өчен резерв мәйданнар булдыру;

4) хәрби каберлекләрдән читтә урнашкан һәм Мәңгелек ут яисә Хәтер уты булган мемориаль корылмаларны үзәкләштерелгән исәпкә алуны оештыру максатларында Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән үзара хезмәттәшлек итү;

5) җирле үзидарә органнары карамагындагы Бөек Ватан сугышы һәйкәлләренә, хәрби каберлекләргә мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру;

6) җирле (муниципаль) әһәмияттәге Бөек Ватан сугышы һәйкәлләрен саклап калу һәм реставрацияләү, аларны Бөек Ватан сугышында совет халкының Җиңүе турында истәлеккә карата лаеклы һәм ихтирамлы мөнәсәбәтне күрсәткән хәлдә тоту;

7) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр.

6 статья. **Татарстан Республикасы Хәтер китабы**

1. Гражданнарда Ватаныбыз тарихына карата хөрмәт уяту һәм ныгыту, Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Хәтер китабы чыгарыла.

2. Татарстан Республикасы Хәтер китабын алып бару һәм саклау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан раслана.

3. Җирле үзидарә органнары муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең Хәтер китапларын чыгарырга хокуклы.

7 статья. **Дәүләт оешмаларына һәм муниципаль оешмаларга, урамнарга һәм мәйданнарга, географик объектларга Ватанны саклаганда һәлак булганнар исемнәрен бирү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларга Ватанны саклаганда һәлак булганнар исемнәрен бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Тиешле муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларга Ватанны саклаганда һәлак булганнар исемнәрен бирү тәртибе муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Урамнарга һәм мәйданнарга Ватанны саклаганда һәлак булганнар исемнәрен бирү муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы территориясендәге географик объектларга Ватанны саклаганда һәлак булганнар исемнәрен бирү «Географик объектлар исемнәре турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

8 статья. **Татарстан Республикасы территориясендәге Бөек Ватан сугышы һәйкәлләренең, хәрби каберлекләрнең сакланышын тәэмин итү**

1. Бөек Ватан сугышы һәйкәлләренә Бөек Ватан сугышы вакыйгалары, анда катнашучылар, аның ветераннары һәм корбаннары истәлеген мәңгеләштерүче скульптура, архитектура корылмалары һәм башка мемориаль корылмалар һәм объектлар, шул исәптән Бөек Ватан сугышы елларында Ватанны саклаганда һәлак булганнар каберлекләре һәм Бөек Ватан сугышы корбаннары каберлекләре күрсәтелгән каберлекләрдә урнашкан кабер ташлары, һәйкәлләр, стелалар, обелисклар, киртә өлешләре һәм башка мемориаль корылмалар һәм объектлар белән бергә, керә.

2. Бөек Ватан сугышы һәйкәленә Бөек Ватан сугышы һәйкәле турында мәгълүматны үз эченә алган язмалар һәм билгеләр урнаштырылган булырга тиеш. Мәгълүмати язмаларда һәм билгеләрдә Бөек Ватан сугышы һәйкәлләре урнаштыру өчен нигез булган вакыйгалар турында белешмәләрне үз эченә алган тарихи

белешмә, Ватанны саклаганда һәлак булганнарның батырлыгы турында мәгълүмат һәм башка белешмәләр (тарихи документларны һәм фотоматериалларны кертеп) булырга тиеш. Мәгълүмати язмаларда һәм билгеләрдә шулай ук булган вакыйгалар һәм күрсәтелгән затлар турында тарихи белешмәне, видеоматериалларны һәм башка материалларны үз эченә алган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмат ресурсларына күчүне тәэмин итә торган график идентификаторлар – QR-кодлар булырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре кысаларында Бөек Ватан сугышы һәйкәлләрен саклап калу, аларны Бөек Ватан сугышында совет халкының Җиңүе турында истәлеккә карата лаеклы һәм ихтирамлы мөнәсәбәтне күрсәткән хәлдә тоту өчен җаваплы.

4. Бөек Ватан сугышы һәйкәлләрен саклап калу һәм реставрацияләү региональ әһәмияттәге һәйкәлләргә – Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге һәйкәлләргә җирле бюджетлардан акчалар бүлеп бирү, шулай ук физик һәм юридик затларның иганәләре белән тәэмин ителә.

5. Ватанны саклаганда һәлак булганнар каберлекләре аларда урнашкан кабер ташлары, һәйкәлләр, стелалар, обелисклар, киртә өлешләре һәм башка мемориаль корылмалар һәм объектлар белән бергә хәрби каберлекләр була.

6. Хәрби каберлеккә хәрби каберлек турында мәгълүматны үз эченә алган язмалар һәм билгеләр урнаштырылган булырга тиеш. Мәгълүмати язмаларда һәм билгеләрдә мемориаль корылмалар һәм объектлар урнаштыру өчен нигез булган вакыйгалар турында белешмәләрне үз эченә алган тарихи белешмә, Ватанны саклаганда һәлак булганнарның батырлыгы турында мәгълүмат һәм башка белешмәләр (тарихи документларны һәм фотоматериалларны кертеп) булырга тиеш. Мәгълүмати язмаларда һәм билгеләрдә шулай ук булган вакыйгалар һәм күрсәтелгән затлар турында тарихи белешмәне, видеоматериалларны һәм башка материалларны үз эченә алган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмат ресурсларына күчүне тәэмин итә торган график идентификаторлар – QR-кодлар булырга мөмкин.

7. Бөек Ватан сугышы һәйкәлләренә, хәрби каберлекләргә мәгълүмати язмалар һәм билгеләр кую бурычы тиешле Бөек Ватан сугышы һәйкәлләре һәм хәрби каберлекләр беркетелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына һәм җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

8. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) дип танылган хәрби каберлекләрне саклап калуны тәэмин итү максатларында алар урнашкан урыннарда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәдәни мирас объектларын саклау зоналары билгеләнә.

9. Хәрби каберлекләргә зыян килү ихтималы булган капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә ярашлы рәвештә башкарыла, ә хәрби каберлекләргә зыян килү ихтималы булган җир, юл эшләре һәм башка эшләр җирле үзидарә органнары белән килештерелгәннән соң гына башкарыла.

10. Яраксыз хәлгә килгән Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүче хәрби каберлекләр, мемориаль корылмалар һәм объектлар җирле үзидарә органнары тарафыннан торгызылырга тиеш.

11. Гражданнар һәм юридик затлар хокукка ия булган җир кишәрлекләрендәге хәрби каберлекләрнең сакланышы өчен җаваплы.

9 статья. **Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү өлкәсендә агарту**

1. Татарстан Республикасында, яшьләрдә Ватаныбыз тарихына һәм туган як тарихына карата хөрмәт, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы өчен горурлык тәрбияләү, тарихның буыннан-буынга тапшырылуын саклап калу, Ватанны саклаганда һәлак булганнарның батырлыкларын, каһарманлыгын һәм кыюлыгын пропагандалау максатларында, Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү өлкәсендә агарту чаралары, шул исәптән батырлык дәресләре, ачык лекцияләр, үткәрелә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чаралар Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп үткәрелә һәм Россиянең хәрби дан көннәренә һәм истәлекле даталарына, Татарстан Республикасының истәлекле даталарына багышланырга мөмкин.

10 статья. **Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү чараларын финанс белән тәэмин итү**

Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү белән бәйле чаралар үткәрүгә, шул исәптән Ватанны саклаучылар батырлыклары белән тарихи бәйләнеше булган аерым территорияләрнең һәм объектларның корылышына, шулай ук күргәзмәләр һәм башка чаралар оештыруга чыгымнар дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары компетенциясенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары хисабына, шулай ук Россия Федерациясе законнарында тыелмаган бүтән чыганаклар хисабына башкарыла.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 19 июнь
№ 36-ТРЗ